**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**05.05.2023** **№ 562**

**Биектау муниципаль районы башкарма комитетының «Гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 13 декабрендәге 1155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә карата таләпләрне билгеләргә хокуклы.

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары белән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр расланды. 2022 елның15 августындагы 1415 карары белән югарыда күрсәтелгән таләпләргә үзгәрешләр кертелде.

Үзгәрешләрне исәпкә алып, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 1.3.3 пунктчасына, түбәндәгене бәян итеп, өченче абзацны өстәргә:

«Формалаштырылган гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче электрон формадагы гарызнамәнең һәр кырны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Шулай ук мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак, аның сайлавы буенча орган (оешма) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган машина укый ала торган форматта бердәм порталны кулланып электрон документ алу мөмкинлеге тәэмин ителә (алга таба - машина укый ала торган форматтагы электрон документ)».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталының рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф.Шәйдуллин